ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«02» октябрь 2023 ел** **№ 838**

**Балаларга өстәмә белем бирү һәм спорт мәктәпләре муниципаль мәгариф учреждениеләренең матди-техник базасын үстерүгә һәм ныгытуга бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү турында**

Арча муниципаль районы балаларының һәм халкының ялын оештыру өчен шартлар тудыру, өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту максатыннан, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү һәм спорт мәктәпләре муниципаль мәгариф учреждениеләренә алар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә килә торган физик һәм (яки) юридик затларның максатчан кертем акчаларын Арча муниципаль районы бюджетыннан муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү буенча факттагы чыгымнарны каплауга юнәлдерүне тәкъдим итәргә.

2. Арча муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү һәм спорт мәктәпләре муниципаль мәгариф учреждениеләренә ремонт эшләрен башкаруга, эшчәнлекнең социаль әһәмиятле төрләрен гамәлгә ашыруга, оешмаларны төзекләндерүгә, гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек кысаларында аларны җиһазлау һәм инвентарь белән тәэмин итүгә ирекле иганәләр (физик һәм (яисә) юридик затларның максатчан кертемнәрен) файдалануны тәкъдим итәргә.

3. Халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә тарифлар күләмен кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «Балаларга өстәмә белем бирү һәм спорт мәктәпләре муниципаль мәгариф учреждениеләренең матди-техник базасын үстерүгә һәм ныгытуга бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү турында» 2020 елның 24 августындагы 625 номерлы карарын;

- «Балаларга өстәмә белем бирү һәм спорт мәктәпләре муниципаль мәгариф учреждениеләренең матди-техник базасын үстерүгә һәм ныгытуга бюджеттан тыш

акчаларны җәлеп итү турында» 2020 елның 24 августындагы 625 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 25 октябрендәге 1088 номерлы карарын.

5. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә һәм 2023 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Гатиятов

1 кушымта

**"Арча спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе**

**Бассейнга бер тапкыр бару (тренерсыз йөзү)**

| Килүчеләр | Бер тапкыр килү бәясе (1 сәгать эчендә) | |
|---|---|---|
| | Бассейн, сум | Бассейн+сауна, сум |
| 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар | 70 | - |
| 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар, мәктәп укучылары | 50 | - |
| Өлкәннәр | 150 | 250 |
| Пенсионерлар | 100 | 200 |
| Ана+бала (3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар) | 150 | - |
| Көндезге уку формасы студентлары | 100 | 200 |

**Йөзү буенча тренер белән шәхси шөгыльләнү**

| Айга шөгыльләнүләр саны | Дәвамлылык 1дәрес, сәгать | Бәясе, сум | |
|---|---|---|---|
| | | Абонемент | Тапкыр |
| 8 | 1 | 3200 | 400 |

**Бассейнга керү абонементы бәясе**
**(тренерсыз йөзү)**

| Абонентлар категориясе | Килүчеләр саны | Бассейн, сум | Бассейн + сауна, сум |
|---|---|---|---|
| Өлкәннәр | 8 | 1050 | 1750 |
| Пенсионерлар | 8 | 700 | 1400 |
| Ана+ бала (3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар) | 8 | 1050 | - |
| Көндезге уку формасы студентлары | 8 | 700 | 1400 |
| 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге | 8 | 490 | - |

| балалар | | | |
|---|---|---|---|

**Тренажерлар залы (стадион)**

| Килүчеләр | Айга шөгыльләнүләр саны | Дәвамлылык 1 нче дәрес, сәгать | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|
| | | | Абонемент |
| Яше буенча чикләүләрсез | 10 | 2 | 500 |

**Фитнес-бокс (тренер белән шөгыльләнү)**

| Килүчеләр | Айга шөгыльләнүләр саны | Дәвамлылык 1дәрес, сәгать | Бәясе, сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Абонемент | Тапкыр |
| Өлкәннәр | 10 | 2 | 3000 | 300 |
| 18 яшькә кадәрге балалар | 10 | 2 | 2000 | 200 |
| Көндезге уку формасы студентлары | 10 | 2 | 2500 | 250 |

**Фитнес (тренер белән шөгыльләнү)**

| Килүчеләр | Айга шөгыльләнүләр саны | Дәвамлылык 1дәрес, сәгать | Бәясе, сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Абонемент | Тапкыр |
| Өлкәннәр | 8 | 2 | 500 | 100 |
| 18 яшькә кадәрге балалар | 8 | 2 | 400 | 60 |
| Көндезге уку формасы студентлары | 8 | 2 | 450 | 70 |

**Спорт төрләре буенча 1 сәгать (тренерсыз) бәясе**

| № | Спорт төре | Килүчеләр | бәясе (бер кешегә), сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Баскетбол | Өлкәннәр | 70 |
| 2 | Волейбол | Өлкәннәр | 70 |
| 3 | Мини-футбол | Өлкәннәр | 70 |
| | | 18 яшькә кадәрге балалар | 50 |

**Спорт залын арендалау**

| Килүчеләр | Бәясе (1 сәгать өчен), сум |
|---|---|
| Өлкәннәр (18 яшь һәм өлкәнрәк) | 1000 |

**Спорт инвентарьларын прокатка алу**

| **Спорт инвентаре төрләре** | **Бәясе (1 сәгать өчен), сум** |
|---|---|
| Йөзү өчен башлык | 20 |
| Йөзү өчен күзлек | 20 |
| Йөзү өчен ластлар | 30 |
| Өстәл теннисы өчен ракеткалар, туплар | 50 |
| Зур теннис өчен туплар, ракеткалар | 50 |
| Футбол тубы | 50 |
| Волейбол тубы | 50 |
| Баскетбол тубы | 50 |
| Жилет | 30 |
| Махсус аяк киеме (сланцы) | 20 |
| Аква-билдәмә | 30 |
| Чаңгы | Өлкәннәр-100<br>18 яшькә кадәрге балалар-50 |
| Роликлы тимераяклар | Өлкәннәр-100<br>18 яшькә кадәрге балалар-50 |
| Самокат | 18 яшькә кадәрге балалар-50 |
| Велосипед | Өлкәннәр-100<br>18 яшькә кадәрге балалар-50 |
| Бильярд | Өлкәннәр-100<br>18 яшькә кадәрге балалар-50 |
| Өстәл теннисы (өстәл) | Өлкәннәр-100<br>18 яшькә кадәрге балалар-50 |
| Зур теннис (корт) | Өлкәннәр-100<br>18 яшькә кадәрге балалар-50 |

**Аква-аэробика (тренер белән дәресләр)**

| **Килүчеләр** | **1 дәреснең озынлыгы** | **Бәясе** |
|---|---|---|
| Өлкәннәр | 1 сәгать | 350 сум |

| | | |
|---|---|---|
| | | |

**Спорт төрләре буенча тренировка дәресләре (тренер белән төркемдә)**

| Килүчеләр | Спорт төре | Аена дәресләр саны | 1 дәреснең озынлыгы, минут | Аена абонемент бәясе, сум |
|---|---|---|---|---|
| Яшь буенча чикләүсез | Футбол<br>Тхэквондо<br>Йөзү | 8<br>8<br>8 | 45<br>45<br>45 | 1300<br>1300<br>1300 |

**«Арча Арена спорт мәктәбе»**
**өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе**

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Халыкның категориясе | Булу озынлыгы, сәгать | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Прокатка тимераяклар бирү | Яшь буенча чикләүсез | 1 | 50 |
| 2 | шугалакта шуу | Яшь буенча чикләүсез | 1 | 100 |
| 3 | Шугалакны прокатка бирү | Корпоратив шуу | 1 | 3000 |
| | | Читтән килүчеләр | 1 | 3000 |
| | | Арча МР һәм Арча шәһәрендә яшәүчеләр өчен | 1 | 2000 |
| 4 | Тимераякларны үткенләү (пар) | Өлкәннәр | | 100 |
| | | Өлкәннәр (ярышлар вакытында) | | 150 |
| | | 16 яшькә кадәрге балалар | | 50 |
| 5 | Душ | | 30 минут | 50 |
| 6 | Шугалак прокаты вакытында өстәмә чишенү бүлмәсе бирү | Шугалак арендаторлары өчен | 1 | 700 |
| 7 | Хоккей матчы карау | | 1,5 | 30 |
| 8 | Хоккей турниры карау | | 1 көн | 50 |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Укучылар сарае» муниципаль өстәмә белем бирү бюджет учреждениесе**

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Халыкның категориясе | Булу вакыты | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Спорт залын һәм спорт җиһазларын прокатка бирү | 18 яшь һәм өлкәнрәк | 1 сәгать | 50 |
| 2 | Спортзалны һәм спорт җиһазын прокатка алу (төркем дәресе) | 18 яшь һәм өлкәнрәк | 1 сәгать | 1000 |
| 3 | Осталык дәресләрендә катнашу | Яшь буенча чикләүсез | Осталык дәресләре | 100 |
| 4 | Видеога төшерү | Яшь буенча чикләүсез | 1 сәгать | 100 |
| 5 | Монтаж белән видеога төшү | Яшь буенча чикләүсез | 1 сәгать | 200 |
| 6 | Репортаж рәвешендә видеога төшерү | Яшь буенча чикләүсез | 1 сәгать | 250 |

**"Арча балалар сәнгать мәктәбе" муниципаль өстәмә белем бирү бюджет оешмасы**

| № | Предметның исеме | Бәясе |
|---|---|---|
| 1. | "Абитуриент мәктәбе". Рәсем сәнгате юнәлеше буенча югары уку йортларына, махсус уку йортларына укырга керүчеләрне әзерләү<br>– 14 яшьтән 17 яшькә кадәрге балалар | 500 сум |
| 2. | Костюмнарны прокатка бирү | 200 - 500 сум (комплект өчен) |
| 3. | Фонограмма яздыру | 800 сум |

**2023 елның 01 сентябреннән башлап 2023/24 уку елына максатчан ата-ана кертеменең тәкъдим ителә торган күләмнәре**
**(ирекле иганәләр)**

**1. «Арча балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы**

| Сәнгать - эстетик юнәлештәге төрләр | 2023 елның 01 сентябренә аена бер укучыга кертем күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | Балалар сәнгать | Шәһәрнең гомуми белем бирү мәктәпләре, балалар | Авыл мәктәпләре |

| | мәктәбе базасында | бакчалары базасында | базасында |
|---|---|---|---|
| - фортепиано, синтезатор, баян, аккордеон, гитара, скрипка, вокал. | 500 | 400 | 300 |
| - әзерлек бүлеге | 800 | - | - |
| домра, балалайка | 400 | 300 | 300 |
| - хореография бүлеге | 500 | 400 | 300 |
| - сәнгать бүлеге | 500 | 300 | 300 |
| - сәнгать бүлеге (агачка бизәк төшерү) | 400 | 300 | 300 |
| - мандолина, курай, гармун һ.б. татар уен кораллары | 400 | 300 | 200 |
| - театр бүлеге | 400 | 300 | 300 |
| -хореография әзерлеге бүлеге | 500 | 400 | - |
| - хореография бүлегенең концерт төркеме | 500 | - | - |
| - "Һөнәрчелек планетасы" мода театры | 500 | - | - |

Максатчан ата-ана кертеме агымдагы айның 10 числосыннан да соңга калмыйча кертелә (җәйге каникуллар вакытын исәпкә алмыйча).

Авыру сәбәпле дәресләр калдырылган очракта, кертемнән азат итү өчен, ата-аналар гариза һәм авыру факты буенча медицина белешмәсен тапшырырга тиеш.

«Арча балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасында ата-аналарның максатчан кертемнәрее буенча түбәндәге ташламалар билгеләнә:

1.1. - Беренче балага максатчан кертем 100% тәшкил итә;
- аннан соңгыларына 50%;
- күпбалалы гаиләдә белем алучы бер бала өчен ташлама бала балигъ булганга кадәр 30% тәшкил итә.

1.2. Оешманың педагогик советы карары буенча, аз тәэмин ителгән гаилә балалары, инвалид балалар, ятим балалар, шулай ук ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар ата-аналарның максатчан кертемнәреннән азат ителә.

1.3. Әлеге карарда каралмаган вәзгыять индивидуаль каралырга мөмкин.

1.4. Ата-аналарның ремонт эшләрен уздыруда, эшчәнлекнең социаль әһәмиятле төрләрендә, оешманы төзекләндерүдә, инвентарь һәм җиһазлар сатып алуда катнашу рәвешендә әлеге карар белән билгеләнгән күләмнәрдә максатчан ата-ана кертеме шартнамә нигезендә мөмкин.

358154 952300

ПРОКУРАТУРА РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ПРОКУРАТУРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**ПРОКУРАТУРА**
**АРСКОГО РАЙОНА**
Галактионова ул., 1, Арск, 422000

Руководителю исполнительного комитета Арского муниципального района Республики Татарстан

Гатиятову Р.М.

05.09.2023 №01-01-2023/652-23-20920009

На № 3491 от 01.09.2023

Сообщаю, что прокуратурой района рассмотрены проекты следующих постановлений исполнительного комитета Арского муниципального района:

- «О привлечении внебюджетных средств на развитие и укрепление материально-технической базы муниципальных образовательных учреждений дополнительного образования детей и спортивных школ»;
- «О внесении изменений в постановление исполнительного комитета Арского муниципального района от 14.03.2022 №170 «Об условиях оплаты труда работников муниципальных образовательных организаций Арского муниципального района».

Содержащиеся в проектах постановлений нормы достаточны для достижения цели правового регулирования. Правила юридической техники соблюдены. Проекты постановлений не содержат коррупциогенных факторов. Нарушений федерального и республиканского законодательства не выявлено.

Замечаний по рассмотренным проектам НПА не имеется.

Прокурор района
старший советник юстиции Р.Р. Каримов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
Сертификат 008EC76DF51446A58217FE0A3A0CB23C90
Владелец **Каримов Ринат Раисович**
Действителен с 13.12.2022 по 07.03.2024

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
вх № 606
дата 05 09 2023

Р.Н. Юсупов, тел.: (84366) 3-21-80

Прокуратура Арского района Республики Татарстан
№ 01-01-2023/652-23-20920009